**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Андреевка авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«10» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге Андреевка авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Элек расланган гражданнар җыеннарында чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегенең Андреевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 октябрендәге 1 номерлы карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегенең Андреевка торак пунктында гражданнар Җыенының 2023 елның 24 октябрендәге 2 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегенең Андреевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

Халык җыенында рәислек итүче Н.И. Егорова

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Н.И. Егорова